КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1454

Федор Шаляпин исемендәге
Республика премиясе турында

Музыкаль һәм вокаль сәнгатьнең яшь эшлеклеләренең иҗади потенциалын стимуллаштыру, вокаль сәнгать традицияләрен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясе 2023 елдан башлап ике елга бер тапкыр бирелә.
2. Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясен бирү буенча комиссия төзергә.
3. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:
Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясе турында нигезләмә;
Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе турында нигезләмә;
Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе составы.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 10 ноябрь, 1454 нче
карары белән расланды

Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясе турында нигезләмә;

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясе (алга таба - Премия) музыкаль һәм вокаль сәнгать өлкәсендәге казанышлар өчен, җырчы культурасын саклау һәм популярлаштыру, музыкаль культураны үстерү буенча актив эшчәнлек алып барган өчен 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге (шул яшьне кертеп) Россия Федерациясе гражданнарына бирелә.

1.2. Премия Премия алуга кандидатны тәкъдим итү турындагы гаризаларны (алга таба – гариза) карау нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең  кушымтасы нигезендә форма буенча бирелә.

1.3. Премия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясен  бирү комиссиясе (алга таба - Комиссия) тәкъдиме буенча бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Премия бирү турындагы карарына, әгәр премия бирелгән кандидат (затлар) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат дип танылган очракта, акчалата бүләкләү, диплом, таныклыгы тапшырылганга кадәр үзгәреш кертелергә мөмкин.

1.4. Премия шәхси характер йөртә һәм ике елга бер тапкыр һәрберсе 200 мең сум күләмендә ике премия күләмендә бирелә.

1.5. Премиягә лаек булган затларга “Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясе лауреаты” исеме бирелә, акчалата бүләк, диплом һәм таныклык тапшырыла.

1.6. Премияне бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.7. Премия бирү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чараларын төп бүлүче, кандидатлар сайлап алуны оештыручы - Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба - вәкаләтле орган).

## II. Премиягә кандидатларны тәкъдим итү тәртибе

2.1. Премияне алу өчен башкаручы әлеге Нигезләмәнең 1.1 пункты нигезендә тәкъдим ителергә мөмкин.

2.2. Премияне алу өчен үлгәннән соң тәкъдим ителми.

2.3. Мәдәният өлкәсендә дәүләт әһәмиятендәге башка премияләренә лаек булган  башкаручы Премия бирелгән елда  Премиягә тәкъдим ителә алмый.

2.4. Премия аның лауреатларына кабат бирелми.

2.5. Премия алуга тәкъдим ителә торган затның яше Комиссия карары кабул ителгән көнгә 35 яшьтән артмаска тиеш.

2.6. Премия алуга кандидатларны күрсәтү Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы мәдәният оешмалары, мәгариф, иҗтимагый, фәнни оешмалар тарафыннан башкарыла.

2.7. Премиягә кандидатлар оешмаларның коллегияләр, президиумнар, идарәләр, сәнгать һәм галимнәр советлары утырышларында, хезмәт коллективлары җыелышларында тәкъдим ителә.

2.8. Тәкъдимне алуга кандидатка карата тәкъдим итүче оешма документларның һәм материалларның түбәндәге комплектын формалаштыра:

әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә гариза;

Премияне алуга кандидатны күрсәтү турындагы оешманың карары;

Премиягә кандидатның иҗади эшчәнлеге турында белешмә;

Премиягә кандидатның иҗади портфолиосы (репертуар, концерт программасы, фоторәсемнәр, аудио-һәм видеоматериаллар, башка күрсәтмә материал);

Премиягә кандидатның иҗатын җәмәгатьчелек тарафыннан танылуын раслаучы материаллар (публикацияләр, рецензияләр, массакүләм мәгълүмат чараларында фикерләр, белгечләр бәяләмәләре);

Премиягә кандидатның Россия Федерациясе гражданы паспорты яки шәхесен таныклаучы башка документы күчермәсе;

музыкаль белем турында (булган очракта) документның (аттестат һәм (яисә) дипломның) күчермәсе;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча гражданның бурычы булмавы турында белешмә;

вәкаләтле орган боерыгы белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Документлар һәм материалларга исемлек бирелә.

2.9. Бер оешма тарафыннан Премиягә берничә кандидатны тәкъдим иткәндә аларның һәркайсына әлеге Нигезләмәнең 2.8 пунктында күрсәтелгән документларның һәм материалларның аерым комплекты формалаштырыла.

2.10. Премия алуга кандидатның документлары һәм материаллары Премияне кәгазь рәвештә яисә почта элемтәсе (курьер хезмәте) ярдәмендә вәкаләтле органга түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт, 114 кабинет.

2.11. Әлеге Нигезләмәнең 2.8 пунктында күрсәтелгән Премиягә тапшырылган кандидат документлары һәм материаллары рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

2.12. Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң вәкаләтле органга кергән документлар һәм материаллар (шул исәптән почта аша, курьер хезмәте аша) каралуга рөхсәт ителми.

## III. Конкурста җиңүчеләрне билгеләүнең төп критерийлары

3.1. Вәкаләтле орган боерыгы белән ел саен 24 ноябрьгә кадәр эксперт советы раслана.

3.2. Эксперт советының максаты - Премияне бирү буенча карар кабул итүдә Комиссиягә ярдәм күрсәтү.

3.3. Эксперт советы составына вәкаләтле орган, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, мәгариф оешмалары белгечләре һәм Комиссия составына кермәгән һәм Премиягә кандидатлар булмаган җәмәгатьчелек вәкилләре керә.

3.4. Вәкаләтле орган заявкаларны кабул итү срогы тәмамлану датасыннан исәпләнә торган өч көн эчендә эксперт советына кергән документларны һәм материалларны тапшыра.

3.5. Тапшырылган документлар һәм материаллар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә Эксперт советы тарафыннан карала.

Эксперт советы аңа документлар һәм материаллар тапшырганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Комиссиягә Премиягә кандидатлар рейтингын (алга таба – рейтинг) тәкъдим итә.

3.6. Сайлап алуга кертелгән Премиягә кандидатлар эксперт советы тарафыннан 10 баллы шкала (0-10) буенча түбәндәге критерийлар буенча бәяләнәләр:

музыкаль программаның башкару осталыгының югары дәрәҗәсе (0 - 10 балл);

музыкаль белем булу (0 - 10 балл);

сәхнәдә эшләү тәҗрибәсе булу (0 - 10 балл);

репертуарда Федор Шаляпинның музыкаль мирасыннан җырлар булу (0 - 10 балл);

репертуарда танылган россия композиторлары әсәрләре булу (0 - 10 балл);

массакүләм мәгълүмат чараларында уңай публикацияләр, рецензияләр, бәяләмәләр булу (0 - 10 балл).

3.7. Рейтинг Премиягә кандидатлар җыйган баллар саны нигезендә формалаштырыла. Балларның гомуми саны әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча Премиягә кандидатлар җыйган баллларны суммалау юлы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 10 ноябрь, 1454 нче
карары белән расланды

Федор Шаляпин исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Фәйзрахманов Айрат Шамил улы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Александровская Ирина Алексеевна | «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Ганиева Винера Әхәт кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең ялгыз халык җырлавы кафедрасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Дулат-Алеев Вадим Робертович | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Җәппаров Айрат Әгъзам улы | «И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Кәлимуллин Рәшид Фәһим улы | «Россия Федерациясе Композиторлар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының идарә рәисе, «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мифтахова Зәлия Зөфәр кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә караган мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерү бүлекчәсе мөдире |
| Мөхәммәтҗанов Рәүфәл Сабир улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Сладковский Александр Витальевич | «Татарстан Республикасы Дәүләт академия симфоник оркестры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең сәнгать җитәкчесе - баш дирижеры |
| Тәминдарова Миләүшә Әмир кызы | «Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Дәүләт камера хорының сәнгать җитәкчесе. |

______________________________